Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

КАРАР № 3-1

Бәтке авылы 18.06.2024

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2023 елның 02 маендагы “Җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 6-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Төбәк салымнары суммалары өлешендә әҗәтне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Бәтке авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2023 елның 02 маендагы “Җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 6-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) түбәндәге эчтәлектәге 2 пунктны өстәргә:

“2. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, каплау һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне (бурычларны) түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бирәчәкләр булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 маддәсендә билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч (әҗәт) булу.”;

1.2) 2, 3, 4, 5 пунктларны тиңдәшле рәвештә 3, 4, 5, 6 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов